Раслыйм: Әтнә муниципаль районы
Мәдәният йорты җитәкчесе
Бариева И.М.

Раслыйм: Әтнә муниципаль районы
"Мәктәптән тыш эшләр үзәге" директоры
Гиниятова С.З.

Килешенде: Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә урта мәктәбе директоры
Халикова Г.Д.

" 2023 ел -Татарстан Республикасында
милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы "
уңаеннан оештырылган
**"Гаилә кыйммәтләре"**
дип исемләнгән мәдәни чараның

**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

1. **Гомуми нигезләмә**

"Рухи кыйммәтләрне саклау, ныгыту, милли традицияләрне торгызу мөһимлеген игътибарага алып, Россия халыкларының мәдәни мирасы елын дәвам итеп, 2023 елны Татарстанда милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан итәм," дип мөрәҗәгать итте Р.Миннеханов Дәүләт Советына еллык юлламасында.

"Мәктәптән тыш эшләр үзәге"нең техник юнәлеш берләшмәләре өчен дә милли гореф – гадәтләрне өйрәнү, халкыбызның рухи хәзинәсен дәвам итү эше чит түгел. Укучылар белән туган төбәкнең милли компонентларын өйрәнүгә зур өлеш бирелә. Бу юнәлешнең берләшмә җитәкчеләре һәм Яңа Әтнә мәдәният йорты тарафыннан әзерләнгән "Гаилә кыйммәтләре" исемендәге мәдәни чара укучы балаларны тәрбияләү – мәгариф һәм мәдәният оешмаларының, әти - әниләрнең бердәм эшчәнлеге икәнлеген раслап, районыбыз мәдәни йортлары җитәкчеләре һәм берләшмәдә укучы өлкән сыйныф укучылары өчен оештырыла.

2. **Максат һәм бурычлар**

- бала белән ата-ана арасында мәхәббәт һәм гаилә бердәмлегенең кеше тормышында иң мөһим урын алып торганлыгын күрсәтү;
- өлкәннәргә карата ихтирам хисләре тәрбияләү;
- истәлекләр белән уртаклашу, буыннар арасындагы бәйләнешкә ихтирам арттыру;
- халкыбызның матди булмаган мирасын саклау һәм таныту;
- дини һәм милли кыйммәтләргә хөрмәт арттыру;
- хезмәт кешесенә ихтирам хисләре тәрбияләү;
- күп балалы гаилә тормышы белән таныштыру;

- укучыларда үз милләтенә, теленә, иленә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

3. **Уздырылу урыны һәм вакыты**
   Мәктәптән тыш эшләр үзәге, *Актлар залы*
   *13 февраль, 2023 ел. 14.00 -16.00 сәгатьтә.*
4. **Катнашучылар һәм чакырылган кунаклар**
   - күп еллар бергә яшәгән үрнәк гаиләдән кунаклар,
   - Әтнә районы мәдәният йортлары җитәкчеләре,
   - өлкән сыйныф укучылары
5. **Мәдәни чараның программасы:**
   1. 14.00-14.15 "Гашыйклар көне" уңаеннан әзерләнгән видео презентация белән танышу
   2. 14.15- 15.30 берләшмә җитәкчеләре тарафыннан әзерләнгән "Адәм белән Һава" тапшыруында катнашу
   3. 15.30 тапшыруны йомгаклау, кунакларны озату
   4. 15.30- 16.00 берләшмә укучылары өчен дискотека, кофе–брейк.
6. **Кичәдә катнашучыларга таләпләр**
   Мәдәни чара башланырга 10 минут кала Актлар залына җыйналып бетәргә. Мәктәп эченә керү өчен икенче аяк киеме алып килергә.
   Кичә барышы берләшмә укучылары тарафыннан фото – видеога төшереләчәк.
7. **Чараны оештыручылар**
   Яңа Әтнә мәдәният йорты һәм "Мәктәптән тыш эшләр үзәге"нең техник юнәлеш берләшмә җитәкчеләре.
8. **Кичәне әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы**
   Бәйрәмова Э.Р., Бурангулова А.Р., Садриева Р.Р.